ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**17.11.2017 ел**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 2904**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «2017-2019 елларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында муниципаль хезмәтне үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2017 елның 20 мартындагы 598 номерлы карары белән расланган «2017-2019 елларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында муниципаль хезмәтне үстерү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2019 елларга Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт һәм муниципаль хезмәт үсеше» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 22 ноябрендәге 910 карары, Зеленодольск муниципаль районы Советының 2017 елның 12 октябрендәге 240 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмә нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «2017-2019 елларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында муниципаль хезмәтне үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2017 елның 20 мартындагы 598 номерлы карары белән расланган «2017-2019 елларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында муниципаль хезмәтне үстерү» муниципаль программасына (алга таба - Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Программа паспортында:

1.1) «Программа бурычлары» юлының 3 пунктында «муниципаль хезмәткәрләрнең» сүзләреннән соң «, муниципаль хезмәт, муниципаль

учреждениеләр хезмәткәрләре вазыйфалары булмаган җирле үзидарә органнарында вазыйфалар биләүче хезмәткәрләрнең » сүзләрен өстәргә;

1.2) «Программаны гамәлгә ашыруның көтелә торган ахыргы нәтиҗәләре» юлының 7 пунктында «муниципаль хезмәткәрләрнең» сүзләреннән соң «, муниципаль хезмәт, муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре вазыйфалары булмаган җирле үзидарә органнарында вазыйфалар биләүче хезмәткәрләрнең » сүзләрен өстәргә;

2) Программаның II бүлегенең алтынчы абзацында «муниципаль хезмәткәрләрнең» сүзләреннән соң «, муниципаль хезмәт, муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре вазыйфалары булмаган җирле үзидарә органнарында вазыйфалар биләүче хезмәткәрләрнең » сүзләрен өстәргә;

3) 1 нче кушымтада:

3.1) 3 нче бурыч: «Муниципаль хезмәткәрләрнең, шулай ук кадрлар резервына кертелгән затларның һөнәри һәм идарә компетентлыгын үстерү» юлында «муниципаль хезмәткәрләрнең» сүзләреннән соң «, муниципаль хезмәт, муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре вазыйфалары булмаган җирле үзидарә органнарында вазыйфалар биләүче хезмәткәрләрнең » сүзләрен өстәргә;

4) 2 нче кушымтада:

4.1)3 нче бурыч: «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең (алга таба - муниципаль хезмәткәрләр), шулай ук күрсәтелгән җирле үзидарә органнарының кадрлар резервларына кертелгән затларның һөнәри һәм идарә компетентлыгын үстерү» юлын яңа редакциядә бәян итәргә: «3 нче бурыч: «Муниципаль хезмәткәрләрнең, җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче хезмәткәрләрнең, муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең, шулай ук кадрлар резервына кертелгән затларның һөнәри һәм идарә компетентлыгын үстерү»;

4.2) 1.3.1 пунктының 2 графасына «муниципаль хезмәткәрләрнең» сүзләреннән соң «, муниципаль хезмәт, муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре вазыйфалары булмаган җирле үзидарә органнарында вазыйфалар биләүче хезмәткәрләрнең » сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә буенча бүлек начальнигына Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Х. Сәхибуллин